| Республика Татарстан Чукмарлинское сельское поселение Сармановского муниципального района | | Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

Чукмарлы авылы

**КАРАР**

14 марта 2019 года

№ 10

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә 2018 елның 18 ноябрендәге 198 номерлы җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды.

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы җыю тәртибен (1 нче кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Чукмарлы авыл җирлеге башкама комитеты җитәкчесе

И.Х.Хадиуллин

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы
авыл җирлеге башкарма комитетының
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тэртип Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, 1 группа инвалидлардан, ялгыз өлкән кешеләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлар тыш Һәм аларның саны  авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми санынан 30 проценттан артмаска тиеш, 2019 нчы елның 31 мартына кадәр, җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә түләнә.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (белдерү) бланкы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук почта элемтәсе аша тапшыру яки җибәрү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы (2 нче кушымта) күрсәтелә.

5. Гражданнарның үзара салым акчалары Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык хезмәте идарәсенең лицевой счетына (Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы) күчерелә.

6. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау һәм почта аша күчерүгә хокуклы оешмалар аша, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча) башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары закон тпрафыннан  билгеләнгән тәртиптә түләтерелә.

Сарман муниципаль районы
Чукмарлы
авыл җирлеге башкарма комитетының
карарына 2 нче кушымта

Чукмарлы авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ№_____

Түләүченең Ф.И.Ә.И
______________________________________________________________________
Адресы: ______________________________________________________________
Нигезләмә ____________________________________________________________
Сезгә _________________________ кадәрле вакыт эчендә_________________________
чараны гамәлгә ашыру буенча ___________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК ____________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ____________________________________________
ИНН ________________________________________
КПП ________________________________________
КБК ________________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше
______________________________________________________________________

Җитәкче ___________________ ________________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Чукмарлы авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне _______________ сум күләмендә түләү турында №______ белдерү кәгазе
Түләүченең Ф.И.А.И.
____________________________________________________________
Адресы:_______________________________________________________________
______________________________________________________________________
Кабул ителде «__» ________________ 20__ ел. _________________________________
(түләүченең имзасы/фамилиясе)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше(отрывной корешок) тутырыла һәм Чукмарлы авыл җирлеге башкарма комитетында кала*